СОВЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422060, Республика Татарстан, Сабинский район,
п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru, www.saby.tatarstan.ru

№ 323 от 25.11.2019
на № __от _________

# К А Р А Р

Гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә
алу вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен
Саба муниципаль районы бюджетыннан
шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына
субвенцияләр бирү Кагыйдәләре турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142 маддәсе нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен Саба муниципаль районы бюджетыннан шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына субвенцияләр бирү Кагыйдәләрен расларга.
2. Әлеге карар нигезләмәләре 2020 ел бюджетыннан башлап һәм 2021, 2022 елларның планлы чорына бюджет төзегәндә, раслаганда һәм үтәгәндә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла.
3. Әлеге карарны Интернет челтәрендә - Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

Саба муниципаль районы
Башлыгы урынбасары Р. Р. Закирҗанов

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы
Советының 2019 елның
25 ноябрендә кабул ителгән
323 номерлы карары белән
РАСЛАНГАН

Гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу
вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен Саба
муниципаль районы бюджетыннан шәһәр һәм авыл
җирлекләре бюджетларына субвенцияләр бирү
Кагыйдәләре

1. Әлеге Кагыйдәләр гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджетыннан Саба муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына субвенцияләр бирү максатларын, тәртибен һәм шартларын билгели (алга таба – субвенцияләр, җирлекләр).

2. Субвенцияләр җирлек бюджетларына гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру максатларында бирелә.

3. Җирлекләр бюджетларына субвенцияләр бирү чыгымнарын финанс белән тәэмин итү чыганагы булып, гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга ,Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджетына бирелә торган федераль бюджеттан субвенция тора.

4. Әлеге Кагыйдәләр нигезендә бирелә торган бюджет акчаларының җаваплы оештыручысы булып Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты тора (алга таба – Башкарма комитет).

5. Җирлек бюджетына субвенция күләме, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен бирү турында”гы 2005 елның 30 декабрендәге 146-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына 3 нче кушымта нигезендә, гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен, Татарстан Республикасы муниципаль районнары бюджетларыннан шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына бирелә торган субвенцияләрне муниципаль районнарның җирле үзидарә органнары тарафыннан исәпләү Методикасы нигезендә билгеләнә.

6. Муниципаль район составына керүче җирлекләр бюджетларына субвенцияләрне бүлү, Саба муниципаль районы Советының тиешле финанс елына һәм план чорына муниципаль район бюджеты турындагы карары белән раслана.

7. Субвенцияләр тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм Башкарма комитетка билгеләнгән тәртиптә әлеге Кагыйдәләрнең 2 пунктында каралган максатларга бирелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә җирлекләр бюджетларына бирелә.

8. Гражданлык хәле актлары язмаларын төзү һәм башка юридик яктан әһәмиятле гамәлләр кылу өлешендә, субвенцияләр, түбәндәге чыгымнарны гамәлгә ашыруга бирелә:

- хезмәт өчен түләү һәм хезмәт өчен түләүне хисаплау;
- командировка чыгымнары;
- элемтә хезмәтләре;
- транспорт хезмәтләре;
- коммуналь хезмәтләр;
- мөлкәтне файдалану буенча хезмәтләр;
- мөлкәтне карап тоту буенча эшләр, хезмәтләр;
- башка эшләр, хезмәтләр;
- төп средстволарны сатып алу;
- матди запаслар сатып алу;
- салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр түләү;
- башка чыгымнар.

9. Субвенцияләрне тоту, Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсе (алга таба - Казначейство) территориаль органнарының, җирлекләр бюджетларын үтәүгә касса хезмәте күрсәтү өчен ачылган шәхси счетлары аша гамәлгә ашырыла.

10. Башкарма комитет, казначылыктан финанслауның иң чик күләмнәрен билгеләү өчен чыгым расписаниесен алганнан соң, җиде эш көне эчендә, Казначылыкка, субвенцияләр хисабына, җирлекләр бюджетларына субвенцияләр күчерү өчен касса чыгымына гариза бирә.

11. Җирлекләрнең җирле үзидарә органнары, хисап чорыннан соң килүче айның 5 числосыннан да соңга калмыйча, финанс тәэминаты чыганагы субвенция булган гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле җирлекләрнең бюджетлары чыгымнары турындагы хисапны, Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы белән килешү буенча Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән форма буенча Башкарма комитетка тапшыралар.

12. Башкарма комитетка бирелә торган белешмәләрнең дөреслеге өчен җаваплылык җирлекләрнең җирле үзидарә органнарына йөкләнә.

13. Субвенцияләр бирү шартларын бозган очракта, тиешле акчалар Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә муниципаль район бюджеты кеременә күчерелергә тиеш.

14. Субвенцияләр бирү елыннан соң килүче елның 1 гыйнварына файдаланылмаган субвенцияләрнең калган өлеше, Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән таләпләр нигезендә, муниципаль район бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

15. Субвенцияләр максатчан характерга ия һәм, әлеге Кагыйдәләрнең 2 пунктында күрсәтелгәннәрдән тыш, башка максатларда кулланыла алмый.

16. Субвенцияләрнең максатчан кулланылышын закон нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты һәм Финанс-бюджет палатасы контрольдә тота.